**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» марта 2019 с. Тюлячи № 131

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы гомумбелем бирү муниципаль бюджет учреждениеләрен үзгәртеп кору турында

«Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең 2019нчы елның 11нче мартындагы 82нче санлы хатын һәм аңа теркәлгән документларны караганнан соң, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 57, 58 статьяларына туры китереп, 2012нче елның 29нчы декабрендәге 273нче санлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законның 9 статьясы 1 пунктының 4 подпункты нигезендә, район Башкарма комитетының 2010нчы елның 11нче ноябрендәге 449нчы санлы карары белән расланган Теләче муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен оештыру, үзгәртеп кору, төрен үзгәртү һәм ябу тәртибенә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Үзгәртеп корырга:

1.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа урта гомумбелем бирү мәктәбен – гомумбелем бирү муниципаль бюджет учреждениесен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа балалар бакчасы – мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе белән, хокукларын һәм бурычларын күчереп, берләштерү формасында;

1.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш төп гомумбелем бирү мәктәбен – гомумбелем бирү муниципаль бюджет учреждениесен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш балалар бакчасы – мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе белән, хокукларын һәм бурычларын күчереп, берләштерү формасында.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа урта гомумбелем бирү мәктәбе – гомумбелем бирү муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә (Миннекәева Г.Г.), шулай ук Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш төп гомумбелем бирү

мәктәбе – гомумбелем бирү муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә (Хужин Ю.Р.) юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында үзгәрешләрне теркәгәндә, гариза бирүче буларак, тиешле гаризаларга һәм башка документларга кул куярга, гамәлдәге законнар белән каралган тәртиптә һәм срокларда башка эшләр башкарырга вәкаләтләр бирергә.

3. Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа балалар бакчасына (Закирова Д.М.) һәм мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш балалар бакчасына (Сафина Г.Г.) билгеләнгән тәртиптә:

3.1. Милекне тапшыруның тиешле актларын әзерләп, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына расларга бирүне;

3.2. Әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә учреждениене үзгәртеп кору процедурасы башлануы турында юридик затларның Бердәм дәүләт реестрына язма әзерләп кертүне;

3.3. Учреждениене үзгәртеп кору турында хәбәрне «Дәүләт теркәве вестнигы» басмасында ике мәртәбә айга бер тапкыр кабатлап урнаштыруны тәэмин итәргә.

3.4. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең белем бирү һәм тәрбия программаларының күчүчәнлеген, контингентның һәм төркемнәр санының сакланышын тәэмин итеп, учреждениеләр уставларына үзгәрешләр кертү проектын эшләргә;

3.5. Учреждениенең штат расписаниесенә үзгәрешләр кертергә.

4. Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Югары Кибәхуҗа балалар бакчасына (Закирова Д.М.) һәм мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе – Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Баландыш балалар бакчасына (Сафина Г.Г.) билгеләнгән тәртиптә:

4.1. Учреждениенең милкенә, акча средстволарына, финанс салуларына һәм финанс йөкләмәләренә инвентаризация уздырырга;

4.2. Кредиторларга учреждениенең үзгәртеп корылуы турында язмача хәбәр итәргә;

4.3. Кушылучы юридик затның эшчәнлеге туктатылуга дәүләт теркәве үтәр алдыннан ике айдан да соңга калмыйча булачак үзгәртеп кору турында хезмәткәрләргә язмача хәбәр итәргә.

5. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин